ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ЫК ТАМАГЫ ТОРАК ПУНКТЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

22 ноябрь 2024 ел № 8

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 9 ноябрендәге 11 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылы гражданнар җыены
КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2025 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән , югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан бер тапкыр түләүне 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, үзара салым акчаларын кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( Ык Тамагы авылындагы юлларны кардан чистарту . ЫкТамагы авылына вак таш сатып алу, ташу, тигезләү).

- Урамнарга яктырту җайланмасы урнаштыру (Ык Тамагы авылында яктырткычлар сатып алу, Ык Тамагы авылында урамнарны яктырту җайланмасы урнаштыру).
- Торак пункт территориясен төзекләндерү; (Ык Тамагы авылында үлән чабу хезмәтләре күрсәтү)
- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (ЫкТамагы т.п. сууткәргеч торбалар урнаштыру)

3. Әлеге карарны Бәзәкә авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов